АГЕНТСТВО ИНВЕСТИЦИОННОГО РАЗВИТИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«15» февраля 2016г. № 13-2/2лс

г. Казань

Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт гражданнар хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышы һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү комиссиясе турында

2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт гражданнар хезмәте турында», 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы гамәлләр турында»гы федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы «Дәүләт гражданнар хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышы һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү комиссияләре турында»гы Указына, Татарстан Республикасының 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасының дәүләт гражданнар хезмәте турында»гы законына, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы УП-569 номерлы «Татарстан Республикасының дәүләт гражданнар хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышы һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү комиссияләре турында»гы Указына ярашлы, боерам:

1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт гражданнар хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышы һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү комиссиясе турындагы Нигезләмәне расларга (теркәлә).
2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Т.И.Миңнуллина

Татарстан Республикасы
Инвестицион үсеш
агентлыгының
от «___» ____________ 20__г.
№ _____
Боерыгы белән расланды

**НИГЕЗЛӘМӘ**
**Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждannar хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышы һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү комиссиясе турында**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждannar хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышы һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү комиссиясе турындагы Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендәге дәүләт граждannar хезмәте турында»гы, 2008 ел 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы гамәлләр турында»гы федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы «Дәүләт граждannar хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышы һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү комиссияләре турында»гы Указы, Татарстан Республикасының 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасының дәүләт граждannar хезмәте турында»гы законы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы УП-569 номерлы «Татарстан Республикасының дәүләт граждannar хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышы һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү комиссияләре турында»гы Указы нигезендә эшләнде. Нигезләмә Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының дәүләт граждannar хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тотышы һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү комиссиясенең формалашу һәм эшчәнлек тәртибен билгели (алга таба – Комиссия).

1.2. Комиссия үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының актларына, әлеге Нигезләмәгә, шулай ук Агентлыкның боерыкларына таяна.

1.3. Комиссиянең төп бурычы түбәндәгеләргә булышлык итүдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасының дәүләт граждannar хезмәткәрләренең Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгында (алга таба – дәүләт

хезмәткәрләре, Агентлык) чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү яки көйләү турындагы таләпләрне, шулай ук «Коррупциягә каршы гамәлләр турында»гы Федераль закон, башка федераль законнар (алга таба – эш урынында үз-үзен тотышына таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турында таләпләр) белән билгеләнгән вазыйфаларны үтәүне тәэмин итүгә;

Агентлыкта коррупцияне кисәтү буенча чараларны тормышка ашыруга.

1.4. Комиссия Агентлыкта Татарстан Республикасының дәүләт гражданнар хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) биләүче дәүләт хезмәткәрләренә кагылышлы эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турындагы таләпләрне үтәү белән бәйле мәсьәләләрне тикшерә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм азат ителә торган дәүләт хезмәтен биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән башка).

1.5. Дәүләт органында дәүләт хезмәте билүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм азат ителә торган дәүләт хезмәткәрләренә кагылышлы эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турындагы таләпләрне үтәү белән бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында оешкан эш урынында үз-үзен тотышы һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү комиссиясе тарафыннан карала.

1.6. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу очраклары буенча тикшерүләр үткәрми.

## II. Комиссия составы

2.1. Комиссия составы Агентлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына Комиссия рәисе, Агентлык җитәкчесе Агентлыкта дәүләт хезмәте биләүче Комиссия әгъзалары арасыннан билгеләгән Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре һәм әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә, тигез хокукка ия. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары үти.

2.2. Комиссия составына керәләр:

а) Агентлык җитәкчесенең беренче урынбасары (Комиссия рәисе), Агентлыкның коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфалы кешесе, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгының юридик бүлеге, Агентлыкның җитәкчесе билгеләгән башка бүлекчәләр хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча аппараты бүлекчәсенең вәкиле;

в) эшчәнлеге дәүләт хезмәте белән бәйле булган фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирү оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре).

2.3. Агентлык җитәкчесе Комиссия составына Агентлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилен кертү турында карар кабул итә ала.

2.4. Нигезләмәнең 2.2 пункты астындагы б» һәм «в» пунктлары һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына Агентлык җитәкчесе соравы нигезендә тиешле оешмалар белән килешү буенча куелган тәртиптә кертелә.

2.5. Комиссиянең дәүләт хезмәтен биләмәүче әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән дә ким булмаска тиеш.

2.6. Комиссия составы Комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясау ихтималлыгы булган мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыкмаслык итеп формалаштырыла.

2.7. Комиссия утырышларында киңәшләшү тавышы хокукына ия:

а) Комиссия тарафыннан эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе билгеләгән, Агентлыкта дәүләт хезмәте биләүче ике дәүләт хезмәткәре, Комиссия тарафыннан карала торган әлеге мәсьәләгә кагылышлы дәүләт хезмәте биләүченең аналогик вазыйфалары;

б) Агентлыкта дәүләт хезмәте биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм Комиссия тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча ачыклык кертә ала торган белгечләр; башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфалы кешеләре; үз мәнфәгатьләре булган оешмалар; Комиссия тарафыннан эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе каралачак дәүләт хезмәткәренең вәкиле, - Комиссия рәисенең һәр тәгаен очрак өчен Комиссия тарафыннан карала торган әлеге мәсьәләгә караган дәүләт хезмәткәренең яки Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының үтенече нигезендә Комиссия утырышына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча аерым кабул ителгән карары белән.

2.8. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми санының өчтән икедән дә аз булмаган өлеше катнаша икән, хокуклы булып санала. Комиссия утырышын Агентлыктагы дәүләт хезмәте биләүче дәүләт хезмәткәрләре булган әгъзалары белән генә үткәрергә ярамый.

2.9. Комиссия әгъзасының Комиссия утырышының көн тәртибенә кергән мәсьәләне караганда, турыдан-туры яки читләтеп шәхси мәнфәгате килеп чыкканда, ул утырыш башланганчы бу турыда әйтергә тиеш. Бу очракта Комиссиянең әлеге әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне караганда катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия утырышы үткәрү өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

а) Агентлык җитәкчесенең, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына ярашлы, дәүләт хезмәткәре мәгълүматларының дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү йомгаклары буенча һәм дәүләт хезмәткәренең эш урынында үз-үзен тотышына таләпләрне үтәве, һәм түбәндәге тикшерү материалларын тәкъдим итүе:

дәүләт хезмәткәренең Татарстан Республикасының дәүләт гражданнар хезмәте биләүче дәүләт хезмәткәренә дәгъва итүче гражданнарның Нигезләмәдә каралганча, керемнәр, мөлкәт һәм милек вазыйфалары турында мәгълүматлар, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге УП-702 номерлы Указына ярашлы, Татарстан Республикасының дәүләт гражданнар хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм милек вазыйфалары турындагы мәгълүматларны биргәндә, дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматлар җиткерүе;

дәүләт хезмәткәренең эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәмәве;

б) Агентлыкның куелган тәртиптәге норматив хокукый актына ярашлы, Агентлыкның коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эш өчен җаваплы вазыйфалы кешесенә килгән:

Агентлыкта дәүләт хезмәтен биләүче гражданның Агентлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәте вазыйфалары исемлегенә кергән дәүләт хезмәтен биләгәндә, Агентлыкның боерыгы белән расланганча, дәүләт хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, тормыш иптәшләренең һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм милек вазыйфалары турында мәгълүматлар, коммерция нигезендәге яки коммерция нигезендә булмаган вазыйфаны биләү өчен яисә коммерция нигезендә яки коммерция нигезендә булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга, әгәр бу оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көннән алып, ике ел үткәнгә кадәр аның хезмәт вазыйфаларына керсә, ризалык бирү турындагы мөрәҗәгате;

дәүләт хезмәткәренең, объектив сәбәпләр арксында, тормыш иптәшенең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм милек вазыйфалары турындагы мәгълүматларны күрсәтү мөмкинлеге булмау турындагы гаризасы;

дәүләт хезмәткәренең 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категория гражданнарга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында исәпләр (кертемнәр) ачу, тере акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит илләрнең финанс коралларына ия булу һәм (яки) файдалануны тыю турында»гы Федераль закон таләпләрен әлеге исәпләр ачылган, тере акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклана торган чит ил банкы һәм (яки) финанс кораллары урнашкан чит дәүләтнең, әлеге чит дәүләт законнарына ярашлы, компетентлы органнары карары белән салынган арест, тыюга бәйле, яки аның ихтыярына яки тормыш иптәшенең һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган сәбәпләр аркасында үтәү мөмкинлеге булмавы турындагы гаризасы;

дәүләт гражданнар хезмәткәренең вазыйфаларын башкарганда, мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган һәм китерү ихтималы булган шәхси мәнфәгате барлыкка килүе турындагы белдерүе;

в) Агентлык җитәкчесенең яки Комиссиянең кайсы да булса әгъзасының дәүләт хезмәткәренең эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрен һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турындагы таләпләрне үтәүне тәэмин итүгә яисә

Агентлыкта коррупцияне кисәтү буенча чараларны тормышка ашыруга кагылышлы тәкъдим итү;

г) Агентлык җитәкчесенең дәүләт хезмәткәренең 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт хезмәтен биләүчеләр һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законның 3 маддәсенең 1 өлешендә каралганча, дөрес булмаган һәм тулы булмаган мәгълүматлар бирүе турындараслаучы материалларны тәкъдим итүе;

д) «Коррупциягә каршы гамәлләр турында»гы Федераль законның 12 маддәсенең 4 өлешенә һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 маддәсенә ярашлы, дәүләт органына кергән коммерция нигезендәге яки коммерция нигезендә булмаган оешманың Агентлыкта дәүләт хезмәтен биләүче граждан белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый килешүе төзүе турындагы белдерүе, әгәр әлеге оешма белән дәүләт идарәсенең аерым функцияләре аның Агентлыкта биләгән вазыйфасы вакытында башкарылган хезмәт вазыйфаларына кергән булса, әлеге гражданга Комиссия элегрәк әлеге оешма белән хезмәт һәм гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керергә баш тарткан яки мондый гражданга коммерция нигезендәге яки коммерция нигезендә булмаган вазыйфаны биләүгә яисә коммерция нигезендәге яки коммерция нигезендә булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешүе шартларында эшләр башкаруга ризалык бирү мәсьәләсе Комиссия тарафыннан каралмаган булса.

3.2. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мөрәҗәгать Агентлыкта дәүләт хезмәте биләүче граждан тарафыннан Агентлыкның коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эшләр өчен җаваплы вазыйфалы кешесенә бирелә. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәгән урынының адресы, дәүләт хезмәтеннән азат ителгән көнгә кадәр соңгы ике ел дәвамында биләгән вазыйфалары, коммерция нигезендәге һәм коммерция нигезендә булмаган оешманың исеме, урнашкан урыны, аның эшчәнлек төре, гражданның дәүләт хезмәте биләгән вакытындагы хезмәт вазыйфалары, коммерция нигезендәге яки коммерция нигезендә булмаган оешмага мөнәсәбәтле дәүләт идарәсе буенча функцияләре, килешү төре (хезмәт яки гражданлык-хокукый), аның гамәлдәге вакыты, килешү буенча эшләр (хезмәт) башкарган (күрсәткән) өчен түләнгән сумма. Агентлыкның коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эшләр өчен җаваплы вазыйфалы кешесе мөрәҗәгатьне карап, аның нәтиҗәләре буенча «Коррупциягә каршы гамәлләр турында»гы Федераль законның 12 маддәсе таләпләрен искә алып, мөрәҗәгатькә мотивлаштырылган йомгак әзерли.

3.3. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне дәүләт хезмәтеннән азат ителергә планлаштыручы дәүләт хезмәткәре бирә ала, һәм ул Комиссия тарафыннан бу Нигезләмәгә ярашлы карала.

3.4. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «д» пунктында күрсәтелгән белдерүне Агентлыкның коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эшләр өчен җаваплы вазыйфалы кешесе карый, ул

Агентлыкта дәүләт хезмәте биләүче гражданның «Коррупциягә каршы гамәлләр турында»гы Федераль законның 12 маддәсендәге таләпләрнең үтәлүе турында мотивлаштырылган йомгак әзерли.

3.4.1. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының бишенче кызыл юлында күрсәтелгән белдерүне Агентлыкның  коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эшләр өчен җаваплы вазыйфалы кешесе карап, белдерүне карау нәтиҗәләре буенча мотивлаштырылган йомгак әзерли.

3.4.2. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яки бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының бишенче кызыл юлында һәм «д» пунктында күрсәтелгән белдерүне карау нәтиҗәләре буенча мотивлаштырылган йомгак әзерләү вакытында Агентлыкның  коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эшләр өчен җаваплы вазыйфалы кешесе мөрәҗәгатьне яки белдерүне тәкъдим иткән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмәләшергә, аннан язма рәвештә ачыклыклар кертүне сорарга хокуклы. Мәгълүмат алу өчен Агентлык тарафыннан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм мәнфәгатьләре булган оешмаларга сораулар җибәрелергә мөмкин. Мөрәҗәгать яки белдерү, шулай ук йомгак һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки белдерү кергән көннән алып җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә кертелә. Сораулар җибәрелгән очракта, мөрәҗәгать яки белдерү, шулай ук йомгак һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерү кергән көннән алып 45 көн эчендә кертелә. Күрсәтелгән вакыт Комиссия рәисе тарафыннан озайтыла ала, әмма 30 көннән дә күбрәк вакытка түгел.

3.5. Комиссия рәисе Комиссия утырышы үткәрү өчен нигезе булган мәгълүмат килеп кергәндә:

а) 10 көн вакыт эчендә Комиссия утырышының көнен билгели. Шул ук вакытта Комиссия утырышының вакыты бу Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән алып 20 көннән дә соңга калмыйча билгеләнә ала;

б) Комиссия тарафыннан эш урынында үз-үзен тотышына таләпләр һәм мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү мәсьәләсе каралачак дәүләт хезмәткәрен, аның вәкилен, Комиссия әгъзаларын һәм Комиссия утырышында катнашучы башка кешеләрне Агентлыкның  коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эшләр өчен җаваплы вазыйфалы кешесенә килгән мәгълүмат һәм аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) Бу Нигезләмәнең 2.7 пункты астындагы «б» пунктында күрсәтелгән затларны Комиссия утырышына чакыру турындагы үтенечләрне карый, аларны канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында һәм Комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау (караудан баш тарту) турында карар кабул итә.

3.6. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының өченче һәм дүртенче кызыл юлларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр, мөлкәт һәм милек вазыйфалары турындагы

мәгълүматлар өчен куелган вакыт узган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

3.7. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «д» пунктында күрсәтелгән белдерү, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.

3.8. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, эш урынында үз-үзен тотышына таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү буенча таләпләрне үтәү мәсьәләсе каралачак дәүләт хезмәткәре, яки Агентлыкта дәүләт хезмәтен биләүче граждан катнашлыгында үткәрелә. Комиссия утырышында шәхсән үзе катнашу нияте турында дәүләт гражданлык хезмәткәре яки граждан бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктына ярашлы мөрәҗәгатендә, гаризасында яки белдерүендә күрсәтә.

3.8.1. Комиссия утырышлары дәүләт хезмәткәре яки граждан булмаганда, түбәндәге очракларда үткәрелә ала:

а) әгәр Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктына ярашлы мөрәҗәгатендә, гаризасында яки белдерүендә дәүләт хезмәткәренең яки гражданның Комиссия утырышында шәхсән үзе катнашу нияте турында күрсәтелмәсә;

б) әгәр Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән дәүләт хезмәткәре яки граждан утырышның үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешле рәвештә мәгълүмат алган хәлдә дә Комиссия утырышына килмәсә.

3.9. Комиссия утырышында Агентлыкта дәүләт хезмәтен биләүче дәүләт хезмәткәренең яки гражданның (алар ризалыгы белән) һәм башка затларның ачыклык кертүе тыңлана, әлеге утырышка чыгарылган мәсьәләләргә кагылышлы материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.10. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышнда катнашкан затлар Комиссия эше барышында билгеле булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

3.11. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «а» пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Татарстан Республикасының дәүләт гражданнар хезмәтен биләүче дәүләт хезмәткәре вазыйфасына дәгъва итүче гражданнарның керемнәр, мөлкәт һәм милек вазыйфалары турындагы мәгүлүматлар турындагы, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының 2009 ел 30 декабрендәге Указы белән расланган, Татарстан Республикасының дәүләт гражданнар хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм милек вазыйфалары турындагы мәгълүматлар бирүе турындагы Нигезләмәгә ярашлы, дәүләт хезмәткәре китергән мәгълүматларның дөрес һәм тулы булуын расларга;

б) бу пункт астындагы «а» пунктында телгә алынган Нигезләмәгә ярашлы, дәүләт хезмәткәре китергән мәгүлүматларны дөрес һәм тулы түгел дип расларга. Бу очракта Комиссия Агентлык җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата тәгаен җаваплылык чарасы кулланырга киңәш итә.

3.12. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «а» пунктының өченче кызыл юлында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәсе буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турындагы таләпләрне үтәвен расларга;

б) дәүләт хезмәткәренең эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турындагы таләпләрне үтәмәвен расларга. Бу очракта Комиссия Агентлык җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турындагы таләпләрне бозуның мөмкин түгеллегенә күрсәтергә яисә дәүләт хезмәткәренә карата тәгаен җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.13. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданга коммерция нигезендәге яки коммерция нигезендә булмаган вазыйфаны биләү өчен яисә коммерция нигезендә яки коммерция нигезендә булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга, әгәр бу оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның хезмәт вазыйфаларына кергән булса, ризалык бирергә;

б) гражданга коммерция нигезендәге яки коммерция нигезендә булмаган вазыйфаны биләү өчен яисә коммерция нигезендә яки коммерция нигезендә булмаган оешмада гражданлык-хокукый килешү шартларында эш башкаруга, әгәр бу оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның хезмәт вазыйфаларына кергән булса, ризалык бирүдән баш тартырга һәм баш тартуның мотивын күрсәтергә;

3.14. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының өченче кызыл юлында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең тормыш иптәшенең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм милек вазыйфалары турындагы мәгълүматларны күрсәтмәвенең сәбәбен объектив һәм игътибарга лаек дип табарга;

б) дәүләт хезмәткәренең тормыш иптәшенең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм милек вазыйфалары турындагы мәгълүматларны күрсәтмәвенең сәбәбен игътибага лаек түгел дип табарга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә карата әлеге мәгълүматларны күрсәтү буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәренең тормыш иптәшенең һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм милек вазыйфалары турындагы мәгълүматларны күрсәтмәвенең сәбәбен объектив түгел дип табарга һәм ул әлеге мәгълүматларны күрсәтүдән читләшү юлы булып тора. Бу очракта Комиссия Агентлык  җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата тәгаен җаваплылык чарасы кулланырга киңәш итә.

3.15. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының дүртенче кызыл юлында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Аерым категория гражданнарга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында исәпләр (кертемнәр) ачу, тере акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит илләрнең финанс коралларына ия булу һәм (яки) файдалануны тыю турында»гы Федераль закон таләпләрен үтәргә комачаулый торган хәлләрне объектив һәм игътибарга лаек дип табарга;

б) «Аерым категория гражданнарга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында исәпләр (кертемнәр) ачу, тере акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит илләрнең финанс коралларына ия булу һәм (яки) файдалануны тыю турында»гы Федераль закон таләпләрен үтәргә комачаулый торган хәлләрне объектив һәм игътибарга лаек түгел дип табарга. Бу очракта Комиссия Агентлык җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата тәгаен җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

3.15.1. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының бишенче кызыл юлында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәре хезмәт вазыйфаларын башкарганда  мәнфәгатьләр каршылыгының булмавын таныргa;

б) дәүләт хезмәткәре хезмәт вазыйфаларын башкарганда, шәхси мәнфәгатьләр мәнфәгатьләр каршылыгына китерүен яки шуның ихтималлыгын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яки) дәүләт органы җитәкчесенә мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү яки аның килеп чыгуын булдырмау буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәренең мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турындагы таләпләрне үтәмәвен танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт органы җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата тәгаен җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.16. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «в»пунктында каралган мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия шуңа ярашлы карар кабул итә.

3.17. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «г» пунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында»гы Федераль законның 3 маддәсенең 1 өлешенә ярашлы, дәүләт хезмәткәре күрсәткән мәгълүматларны дөрес һәм тулы дип табарга;

б) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында»гы Федераль законның 3 маддәсенең 1 өлешенә ярашлы, дәүләт хезмәткәре күрсәткән мәгълүматларны дөрес һәм (яки) тулы түгел дип табарга Бу очракта Комиссия Агентлык җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата җаваплылыкның тәгаен чарасын кулланырга һәм (яки) чыгымнарны контрольдә тоту нәтиҗәләре буенча материалларны прокуратура органнарына һәм (яки) компетенцияле башка дәүләт органнарына юлларга киңәш итә.

3.18. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «д» пунктында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия Агентлыкта дәүләт хезмәте биләүче гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) коммерция нигезендәге яки коммерция нигезендә булмаган оешмада аңа вазыйфа биләргә яисә коммерция нигезендә булган яки коммерция нигезендә булмаган оешмада, әгәр бу оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның хезмәт вазыйфаларына керсә, гражданлык-хокукый килешүе шартларында эшләр башкарырга ризалык бирергә;

б) аның коммерция нигезендә булган яки коммерция нигезендә булмаган оешмада хезмәт килешүе шарларында һәм (яки) коммерция нигезендә булан яки коммерция нигезендә булмаган оешмада эшләр башкару (хезмәт күрсәтү) «Коррупциягә каршы гамәлләр турында»гы Федеарль закон таләпләренең 12 маддәсенә каршы килүен расларга. Бу очракта Комиссия Агентлык җитәкчесенә күрсәтелгән хәлләр турында прокуратура органнарына һәм белдергән оешмага хәбәр итәргә киңәш итә.

3.19. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «а»-«д» пунктларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, моның өчен нигезләр булганда, Комиссия бу Нигезләмәнең 3.11 – 3.15.1, 3.17 – 3.18 пунктларында каралганнан тыш башка карар кабул итә ала. Мондый карарны кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышының беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

3.20. Комиссия карарларын башкару өчен Агентлыкның норматив хокукый актларының, Агентлык җитәкчесенең карарлары һәм биремнәре проектлары әзерләнергә мөмкин – алар куелган тәртиптә Агентлык җитәкчесе каравына кертелә.

3.21. Бу Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары (әгәр Комиссия башка карар кабул итмәсә) Комиссия әгъзаларының утырышта катнашкан күпчелегенең гади ябык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

3.22. Комиссия карарлары беркетмәләргә теркәлеп бара, анда утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары имзасын куя. Комиссия карарлары, бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карардан тыш, Агентлык җитәкчесе өчен киңәш буларак бара. Бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карар мәҗбүри рәвештә үтәлергә тиеш.

3.23. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы үткәрелгән көн, утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) Комиссия утырышында карала торган мәсьәләләрнең һәркайсына кагылышлы эш урынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турындагы таләпләрне үтәү мәсьәләсе каралачак дәүләт хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы күрсәтелгән булырга тиеш;

в) дәүләт хезмәткәренә карата дәгъвалар, алар таяна торган материаллар;

г) дәгъвалар буенча дәүләт хезмәткәренең һәм башка затлар биргән аңлатмаларның эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) Комиссия утырышы үткәрү өчен нигез булган мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның дәүләт органына килеп кергән көне;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итү өчен нигез.

3.24. Комиссия әгъзасы кабул ителгән карар белән килешмәгәндә, язмача формада үз фикерен белдерергә хокуклы, ул мәҗбүри рәвештә Комиссия утырышы беркетмәсенә теркәлергә һәм аның белән дәүләт хезмәткәре танышып чыгарга тиеш.

3.25. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе утырыштан соң 7 көн эчендә Агентлык җитәкчесенә, тулысынча яки аннан өземтәләр белән дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары белән мәнфәгатьләре булган башка затларга юллана.

3.26. Агентлык җитәкчесе Комиссия утырышының беркетмәсен карап чыгарга тиеш һәм үзенең компетенциясе кысаларында дәүләт хезмәткәренә карата карар кабул иткәндә, анда Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, шулай ук коррупциягә каршы гамәлләрне оештыруда башка мәсьәләләр буенча җаваплылык чараларын куллану турында рекомендацияләрне искә алырга хокуклы. Комиссиянең рекомендацияләрен каравы һәм кабул ителгән кара турында Агентлык җитәкчесе Комиссия утырышының беркетмәсе кергән көннә алып бер ай эчендә язма рәвештә Комиссиягә белдерү бирә. Агентлык җитәкчесенең карары Комиссиянең чираттагы утырышында яңгыратыла һәм фикер алышып тормыйча исәпкә алына.

3.27. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар хата билгеләре билгеләнгән очракта, бу турыда дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралганча, җаваплылык чаралары куллану мәсьәләсен хәл итү өчен мәгълүмат Агентлык җитәкчесенә җиткерелә.

3.28. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәре тарафыннан административ хокук бозу яки җинаять билгеләре булган гамәлләр факты (гамәл кылмау факты) билгеләнгән очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәл кылу (гамәл кылмау) турындагы мәгълүматны һәм бу фактны раслаучы документларны 3 көн эчендә, кирәк булганда, тиз арада хокук саклау органнарына тапшырырга тиеш.

3.29. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яки аннан өземтәләр эшурынында үз-үзен тотышына карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын көйләү турында таләпләрне үтәү мәсьәләсе каралачак дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә теркәлә.

3.30. Комиссия карарының Комиссия секретаре имзасы һәм Агентлык мөһере белән расланган өземтәсе бу Нигезләмәнең 3.1 пункты астындагы «б» пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән мәсьәлә каралачак, Агентлыкның дәүләт хезмәте биләүче гражданына имза куйдырып тапшырыла яки ул мөрәҗәгатьтә күрсәткән

адрес буенча заказлы хат яки белдерү хаты белән Комиссиянең шуңа ярашлы үткән утырышының икенче көненнән дә соңга калмыйча юллана.

3.31. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларын көн тәртибенә кергән мәсьәләләр, уырышны үткәрү көне, вакыты һәм урыны белән, Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышында фикер алышуга куела торган материаллар белән таныштыру эшләрен Агентлыкның коррупцияне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча эшләр өчен җаваплы вазыйфалы кешесе башкара.